КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 август г.Казань № 931

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары белән расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары

белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 705 нче; 2021 ел, 11 февраль, 70 нче; 2021 ел, 24 май, 366 нчы; 2021 ел, 30 октябрь, 1026 нчы; 2022 ел, 22 гыйнвар, 39 нчы; 2022 ел, 11 июль, 665 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1315 нче; 2023 ел, 21 март, 307 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә, 13 пунктның өченче абзацындагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин